КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 сентябрь г.Казань № 836

Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә
дәүләт ярдәме чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә бөртекле культуралар җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 6 февралендәге 118 нче карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елда бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин